ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.04.2024 с.Старое Дрожжаное №179

2024 елның II кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2024 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2024 елның 12 мартындагы 174/пр номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның II кварталына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләме исәбеннән гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен, «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында авыл җирендә яшәүче, яшь гаиләләр һәм яшь белгечләрнең Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, 31 800 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы Р.Р. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов